**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында

«Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итүне арттыру һәм аны үстерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча чаралар турында» 2006 елның 29 апрелендәге ПУ-165 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 июлендәге ПУ-357 номерлы, 2007 елның 17 декабрендәге ПУ-686 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-208 номерлы, 2012 елның 20 августындагы ПУ-682 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге ПУ-1043 номерлы һәм 2015 елның 17 мартындагы ПУ-290 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Созвездие-Йолдызлык» республика ачык телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивалендә (алга таба – фестиваль) җиңүчеләргә бер тапкыр түләнә торган еллык махсус дәүләт стипендияләрен гамәлгә куярга.

35 стипендия түләнә дип билгеләргә, шул исәптән:

җиде стипендия – һәрберсе унбиш мең сум күләмендә;

җиде стипендия – һәрберсе егерме мең сум күләмендә;

җиде стипендия – һәрберсе егерме биш мең сум күләмендә;

алты стипендия – һәрберсе утыз мең сум күләмендә;

биш стипендия – һәрберсе утыз биш мең сум күләмендә;

бер стипендия – кырык мең сум күләмендә;

«Вокал-соло» номинациясендә Гран-при – бер стипендия җитмеш мең сум күләмендә;

«Хореография» номинациясендә Гран-при – бер стипендия сиксән мең сум күләмендә.»;

б) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча совет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Н.Ө. Мәганов – «В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)»;

Н.Г. Мәһдиев – «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

үз актларын әлеге Указга туры китерергә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм итү буенча өстәмә чаралар турында» 2008 елның 28 апрелендәге ПУ-176 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә. Әлеге Указның 1 пункты «а» пунктчасының һәм 3 пунктының гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 16 октябрь
№ ПУ-992